ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге составына керүче Алгай торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 5 «18» ноябрь, 2021 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Алгай торак пунктында 2021 елның «18» ноябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Алгай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә Алгай авылындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

- ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә Алгай торак пунктында балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;
- ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә Алгай торак пунктында " Өскебаш" елгасы аша чыгучы күпердәге торба өстенә янгын помпасын урнаштыру өчен будка ясау;
-ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә Алгай торак пунктында Зур урамын вакташ җәеп ремонтлау;
- ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә Алгай торак пунктында елга аша җәяүлеләр өчен басмага материаллар сатып алу һәм төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 169 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 91кеше, 54% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 91 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Алгай торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Алгай торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Алгай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә Алгай авылындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

- ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә Алгай торак пунктында балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;
- ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә Алгай торак пунктында “ Өскебаш” елгасы аша чыгучы күпердәге торба өстенә янгын помпасын урнаштыру өчен будка ясау;
-ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә Алгай торак пунктында Зур урамын вакташ җәеп ремонтлау;
- ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегендә Алгай торак пунктында елга аша җәяүлеләр өчен басмага материаллар сатып алу һәм төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Көмеш-Күл  авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл  авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл  авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе — И.Н.Сәләхетдинов.